ЕЛАБУЖСКИЙ
ГОРОДСКОЙ
СОВЕТ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
ШӘҺӘР
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

19.05.2025 ел Алабуга шәһәре № 163

Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлегенең эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2012 елның 13 июлендәге 109 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында "Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында» 2012 елның 13 июлендәге 109 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакындагы Нигезләмәдә:

1.1.1. 1.8. пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган мәгълүматны җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар тарафыннан «Интернет» челтәрендә урнаштыру.

1.1.2. 3.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Җирле үзидарә органнары үз эшчәнлекләре турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» челтәреннән файдалана, анда Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган таләпләргә туры китереп төзелгән электрон почта адресларын күрсәтеп, мәгълүматтан файдаланучы тарафыннан сорау җибәрелергә һәм соратып алына торган мәгълүмат алынырга мөмкин булган рәсми сайтлар төзелә.

Әлеге оешмалар карамагында булган җирле үзидарә органнары карары буенча ведомство буйсынуындагы оешмалар, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми сайтлар төзиләр.

Муниципаль районга керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар эшчәнлеге турында мәгълүмат муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.

Федераль законнар нигезендә бердәм портал булдыру каралырга мөмкин, анда җирле үзидарә органнарының һәм (яисә) ведомство буйсынуындагы оешмаларның берничә рәсми сайты урнаштырырга була».

1.1.3. 1.5 пунктын «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләре белән тулыландырырга.

1.1.4. 1.7 пунктының 4 пунктчасында «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар» сүзләре белән тулыландырырга.

1.1.5. 3.2 пунктын «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «һәм аларга буйсынучы оешмалар» сүзләре белән тулыландырырга.

1.2. 1.3. 2 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бирергә:

«Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында рәсми сайтта урнаштырыла торган мәгълүматлар исемлеге».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш, хокук тәртибе һәм законлылык, шәһәр төзелеше, инфраструктура үсеше һәм торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары К.В. Мокшин